| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«КЕРЛИГАЧСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>РЕШЕНИЕ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«КИРЛЕГӘЧ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ<br>КАРАР |

2022 елның 7 ноябре № 25

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2015 елның 20 ноябрендәге 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Керлигәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә һәм авыл җирлеге территориясенең тиешле санитар торышын тәэмин итү, авыл җирлеге территориясен пычратудан саклау чараларын тормышка ашыру максатыннан, Кирлегәч авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2015 елның 20 ноябрендәге 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Кирлегәч түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) 142 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«142. Умарталарны тоту өчен урыннар (алга таба - умарталыклар) түбәндәге ераклыкта булырга тиеш:

Торак пунктларда яки гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару территорияләрендә (алга таба - бакчачылык яисә яшелчәчелек территорияләре) очу юлын әлеге участоклар чикләреннән капма каршы якка юнәлдереп күршедәге җир кишәрлекләре чикләреннән кимендә 3 метр ераклыкта яки умарталыкларны башка җир кишәрлекләреннән 2 метрдан ким булмаган койма белән аерып алу шарты булганда очу юлын ераклык һәм юнәлеше буенча чикләүләрсез»;

б) 134 пунктта «башка зат» сүзләреннән соң «,яисә терлекләрне көтү өчен билгеләнгән территориядә терлекләрне тоту җайланмасын кулланып» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны Кирлегәч авылы, Совет урамы, 33А йорт (мәдәният йорты бинасы) адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка игълан

итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http:/leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

«Кирлегәч авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе С.Р.Сәлахова